РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 октябрь 2025 ел Буа шәһәре № 6-2

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль милкендәге муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану тәртибенә үзгәрешләр кертү турында (җирле бюджетка керү өлешендә)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 06 маендагы 393 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2020 елның 15 маендагы 6-53 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль милкендәге муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве буенча бурычны һәм пеняны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану тәртибенә (җирле бюджетка кергән өлештә) киләсе үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 өлешнең 2.4. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Комиссия бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Актны өч нөсхәдә рәсмиләштерә, аңа документларны карауда катнашкан комиссия рәисе һәм барлык әгъзалары имза сала.  (1 нче кушымта).»;

1.2. 3 өлешнең  3.1.1. пунктында «(1 нче кушымта)»ны «(2 нче кушымта)»га үзгәртергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат

порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары И.Ф. Еремеевка йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
муниципаль милкендәге муниципаль мөлкәттән һәм
җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве
буенча бурычны һәм пеняны түләтүгә һәм исәптән
чыгаруга өметсез дип тану тәртибенә (җирле бюджетка кергән өлештә)
1 нч екушымта

РАСЛЫЙМ

Җитәкче (башлык)

___________________________________
(имза) (инициаллары, фамилиясе)

М.У.

**Бюджта түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану**
**АКТЫ**

"__" ______________ 20 __ ел N _____

Активлар керү һәм чыгу комиссиясе (алга таба - Комиссия) бюджетка түләүләр буенча бурычны бурычка карата түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү өчен нигезләрне тикшерде:

| N т/б | Оешманың тулы исеме; физик затның Ф. И. А.и. | ИНН, ОГРН, КПП ; физик затның ИНН (булганда) | Бурыч барлыкка килгән түләү турында белешмәләр | Бурычның барлыкка килү датасы | Бюджетка түләүләр буенча бурыч исәпкә алына торган керем коды, керем коды исеме | Түләү буенча бурыч суммасы (пенялар һәм штрафлар буенча бурычны да кертеп)) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

______________________________________________________________________________
(керемнәр администраторының тулы исеме)

______________________________________________________________________________ нигезендә
(тәртипнең 5 пунктында каралган документлар күрсәтелә)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Комиссия карар кабул итте: ____________________________________________________

______________________________________________________________________________

Комиссия әгъзалары: _______________ / _______________ /
(имза) (инициаллары, фамилиясе)

_______________ / _______________ /
(имза) (инициаллары, фамилиясе)